**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КИРОВ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423747, Киров авылы,
Киров урамы,52 йорт.
тел.факс.: (85552) 3-44-47
e-mail: kirov.sp@yandex.ru

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КИРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

423747, пос. совхоз им. Кирова,
ул. Кирова, дом 52.
тел.факс.: (85552) 3-44-47
e-mail: kirov.sp@yandex.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**От 27.05.2025ел.**

**КАРАР №10**

«Актаныш муниципаль районы Киров авыл җирлеге башкарма комитетында муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында» Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Киров авыл җирлеге Башкарма комитеты 12.02.2013 ел 7 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Актаныш муниципаль районының Киров авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Актаныш муниципаль районы Киров авыл җирлеге башкарма комитетында муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында» Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Киров авыл җирлеге Башкарма комитеты 12.02.2013 ел 7 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.2 бүлегенең 2.11 пунктында "документлардан" сүзеннән соң "һәм (яисә) мәгълүматтан"сүзләрен өстәргә;

1.2. 4 бүлекнең 2-6 абзацларын үз көчләрен югалткан дип танырга;

1.3. 4 бүлекнең 7 абзацында ", шулай ук административ регламентлар проектларында бәйсез экспертиза нәтиҗәләрен исәпкә алуны бәяләүне" сүзләрен төшереп калдырырга.;

1.4. Тәртипнең 2 бүлегенең 7 пунктындагы 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте башкарма органнарының, җирле үзидарә органнарының административ регламентлары проектларын эшләү һәм килештерү Россия Федерациясе субъектының дәүләт хезмәтләре реестрын, муниципаль хезмәтләр реестрын тиешенчә электрон рәвештә алып баруны тәэмин итә торган дәүләт мәгълүмат системасында һәм (яисә) муниципаль мәгълүмат системасында гамәлгә ашырыла».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында "авыл җирлекләре" бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Киров авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе Даутов Д.Н.